СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 11 от 06.10.2020
на № _от _________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Авыл җирендә, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2006 елның 27 декабрендәге 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Мәгариф турында “Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Авыл җирендә, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында” 2006 елның 27 декабрендәге 105 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– карарның 1 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “- педагогик хезмәткәрләргә, белем бирү оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәдәният хезмәткәрләренә, шул исәптән социаль хезмәтләр дәүләт һәм муниципаль системасының социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәткәрләренә – торак, җылылык, ут өчен түләүгә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы, авыл җирлегендә урнашкан мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәгән һәм шунда яшәгән пенсиягә чыккан хезмәткәрләр өчен сакланып кала.”.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы

Р. Н. Минниханов